**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы**

**КАРАР № _15__**

**Урыссу ш. т. п.** **«_08_»__09_____ 2020 ел**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының 23.12.2019 ел № 23 "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" Урыссу шәһәр тибындагы поселогы "муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип кагыйдәләрен раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советы **карар кабул итте** :

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип кагыйдәләрен раслау турында «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының 23.12.2019 ел, № 23 “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында” карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Урыссу шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. Нумерацияне үзгәртеп, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.1. 2.1 пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- территорияне төзекләндерү - Урыссу шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру, гражданнарның яшәү шартларын яхшырту һәм тәэмин итү, шәһәр тибындагы Урыссу поселогы муниципаль берәмлеге территориясенең санитар һәм эстетик торышын яхшырту, шәһәр тибындагы Урыссу поселогы муниципаль берәмлеге территорияләрен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми кулланылыштагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналар, төзелмәләрне, корылмаларны, якын-тирә территорияләрне карап тоту буенча эшчәнлек».

1.2. 2.1 пунктының 28 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- стационар булмаган сәүдә объекты - вакытлыча корылмадан яисә вакытлыча консрукциядән торган, инженерлык-техник тәэминат челтәрләренә тоташтырылуга (технологик тоташтырылуга), шул исәптән күчмә корылмага карамастан, җир кишәрлеге белән ныклап бәйләнмәгән вакытлы корылмадан гыйбарәт сәүдә объекты».

1.3. 2.1 пунктының 40 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« әйләнә - тирә янәшә территория - әгәр мондый җир кишәрлеге барлыкка килгән һәм чикләре Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртип нигезендә "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән очракта, бина, төзелмә, корылма, җир кишәрлеге янәшәсендәге территория.

1.4. 2.1 пунктының 55 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- территорияне төзекләндерү элементлары - декоратив, техник, планировка, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, төрле җиһазлар һәм бизәү элементлары, шул исәптән биналарның, корылмаларның фасадлары, кече архитектура формалары, капиталь булмаган стационар булмаган корылмалар һәм төзелмәләр, мәгълүмат щитлары һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлешләре буларак кулланыла торган күрсәткечләр».

1.5. 3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.4. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм җыештыру «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән башкаручылар тарафыннан гамәлгә ашырыла”.

1.6. 3.7 пунктының б пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгәнгомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр чикләрендә-вәкаләтле орган йә башкаручы”.

1.7. 5 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Юлларны карап тотуны «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 05.04.2013 ел, № 44-ФЗ Федераль закон нигезендә билгеләнгән башкаручылар гамәлгә ашыра”.

1.8. 9.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.6. Тышкы яктыртуның бердәм системасына тоташтырылган урам һәм йорт яны утларын карап тоту һәм ремонтлау эшләрен «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән вәкаләтле орган яисә башкаручы гамәлгә ашыра. Торак йортларның бүлү җайланмаларына тоташтырылган йорт яны яктырткычларын карап тоту һәм ремонтлау эшләрен идарәче оешмалар башкара".

1.9. 10.1.1 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.1.1. Кече архитектура формаларын карап тоту бирелгән җир кишәрлекләре чикләрендә, гомуми файдаланудагы территорияләрдә хокук ияләре тарафыннан гамәлгә ашырыла - «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт

системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән башкаручы белән төзелгән контракт нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан тәэмин ителә.

1.10. 12 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җирләү урыннарын санитар тәртиптә тотуны «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 05.04.2013 ел, № 44-ФЗ Федераль закон нигезендә билгеләнгән башкаручы гамәлгә ашыра."

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы, муниципаль районның рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникацион челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советының торак-коммуналь хуҗалык, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм социаль үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Урыссу шәһәр тибындагы**
**поселогы Башлыгы урынбасары** **Р. М. Гарипов**